Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге

Шигали авыл җирлеге башлыгы
карары

18 декабрь, 2024 ел № 6

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмә белән, Шигали авыл җирлеге Советының 2017 елның 21 августындагы 6 номерлы карары белән расланган (2017 елның 14 декабрендәге 19, 2018 елның 25 маендагы 11, 2019 елның 2октябрендәге 11, 2022 елның 14 декабрендәге 61 номерлы, 2023 елның 31 мартындагы 69 номерлы үзгәрешләр белән), Шигали авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокукларына ия булучыларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге башкарма комитетына гавами тыңлаулар оештыручыларга җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә гавами тыңлаулар оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Гавами тыңлаулар үткәрү 2024елның 18 гыйнварыннан да соңга калмыйча төгәлләнергә тиеш дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Шигали авыл җирлеге башлыгы В.М. Сәлимов